СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2020 елның 30 гыйнвары № 42/6

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм бу муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар аларны биләгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле муниципаль вазыйфалар исемлеге хакында

«Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына дәгъвалаучы гражданнарның, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын яисә җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе хакында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм бу муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар аларны биләгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында

мәгълүмат бирергә тиешле муниципаль вазыйфалар исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2016 елның 9 мартындагы 7/7 номерлы «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында» гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров

Кушымта
Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карары белән расланган
2020 елның 30 январе № 42/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат һәм бу муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар аларны биләгәндә үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле муниципаль вазыйфалар
ИСЕМЛЕГЕ

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы урынбасары, үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Контроль-хисап палатасы Рәисе

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы депутатлары

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе